**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**
**от 25.08.2023** | **№ 1171**

Җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча фикер алышу өчен гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 37, 39 статьяларына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставына таянып, халыкның фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 20 сентябренә 14 сәгать 00 минутка, җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә - «ПК Полигран» ҖЧҖ милкендәге 1653 квадрат метр мәйданлы 16:16:220109:1142 кадастр номерлы җир кишәрлегенә «торак төзелешенә хезмәт күрсәтү» (2.7 коды) рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча фикер алышу өчен гавами тыңлаулар уздыруны түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау т/юл станциясе п., Совет ур., 13 й., 3 кат Красносельский авыл җирлеге администрациясе бинасында билгеләргә.

2. Кызыксынучы затка «Биектау хәбәрләре» газетасында җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча фикер алышу өчен гавами тыңлаулар үткәрелү урыны һәм вакыты турында мәгълүматны бастырып чыгару белән бәйле чыгымнарны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясының 10 пункты нигезендә үз өстенә алырга.

3. Гавами тыңлауларда каралырга тиешле мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне кабул итүне Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл. станциясе п., Совет ур., 13 йорт, 3 кат адресы буенча эш көннәрендә көн саен 08.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр һәм 13.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр 2023 елның 25 августыннан 2023 елның 19 сентябренә кадәр чорда һәм шулай ук 2023 елның 20 сентябрендә турыдан-туры гавами тыңлаулар уздырганда гамәлгә ашырырга.

4. Җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыру буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

1) Нуруллин Р.Ф. - Красносельский авыл җирлеге башлыгы – Рәислек итүче;

2) Никитенко Р.Ф. - Красносельский авыл җирлеге башкарма комитеты башлыгы урынбасары - Секретарь;

3) Хисамутдинов Р.Ш. – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы.

5. Эш төркеменә катнаш кишәрлекләр милекчеләренә хәбәр итәргә (Форма кушымтада бирелә).

6. Эш төркеменә Биектау муниципаль районы территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясенә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча беркетмә һәм бәяләмә әзерләп җибәрергә.

7. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Ф. Хәкимуллин

Хәбәрнамә

Хөрмәтле ___________________________!

Сезгә ____ ___ елның _______ _____ сәгатьтә ___________________ авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында: ______________________________________________ ______________________________ адресы буенча, ___________________ кадастр номерлы, ___________________________________ милкендәге җир кишәрлегенең __________________________________________ ___ мәсьәләсе буенча, Сез катнаш кишәрлек милекчесе булып торуыгыз сәбәпле, гавами тыңлаулар үткәрелүе турында хәбәр итәбез.

Гавами тыңлауларда каралырга тиешле мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне язма рәвештә кабул итү Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл. станциясе п., Совет ур., 13 йорт, 209 каб. адресы буенча эш көннәрендә көн саен 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр ______ елның ___________ нан _______ елның ___________ кадәр чорда һәм шулай ук 2023 елның ___________ турыдан-туры гавами тыңлаулар уздырганда гамәлгә ашырыла.

Гавами тыңлауларда катнашу өчен үзең белән паспорт алырга кирәк.

Барлык туган сораулар буенча 8-84365-23068 телефоны аша яисә Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл станциясе п., Кооператив ур., 5 й. адресы буенча мөрәҗәгать итәргә.

**Хәбәрнамәне алды:**

**Дата_________________**

**Ф.И.А. ___________________________________**

**Имза________________________